Бу тормышта үз юлыбыз,
Үз юлыбызда үз җырыбыз!

# Бу тормышта үз юлыбыз,
# Үз юлыбызда үз җырыбыз!



Кичкетаң урта мәктәбе – 30 елдан артык тарихы булган белем йорты. Ул үзенең тырыш, белемле, һәр эшкә иҗади якын килүче укытучылары, шаян, ихлас, шат күңелле укучылары белән горурлана. Безнең мәктәптә укып чыккан шәхесләр бөтен ил буйлап таралган. Алар арасында төрле һөнәр ияләре бар. Ләкин алар барысы да – шушы оя кошлары. Без үткәнебез белән горурланып, бүгенгебезне төзеп, киләчәккә өметләр баглап яшибез. Без татар җирендә яшәвебез, татар телендә сөйләшүебез белән горурланабыз, укучыларыбыз һәм укытучыларыбыз каләмнәрен туган телдә тибрәтә алулары белән дә бәхетле. Бу җыентыкка укучыларыбыз һәм укытучыларыбыз иҗаты урнаштырылды.





**ТАТАРЛАР ЕЛМАЕП ҮЛДЕЛӘР...**

Елмаеп киттеләр Мусалар,
Күмелде таңнарда йөзләре.
Күкләрдән багалар күк безгә,
Кул изәп дәшә күк үзләре.

Күмелде таңнарда йөзләре,
Ә хәбәр ерактан әйдәде:
“Үлмәдек, үәлмәдек без, иптәшләр,
Богаулар тик тәнне бәйләде!”

Күкләрдән багалар күк безгә,
Яктымы, дип, барыр юлыбыз.
Сез тыныч йоклагыз, абыйлар.
Сез – безнең маяк нурыбыз!

Кул изәп дәшә күк үзләре:
“Бәхетле булыгыз, балалар!”
...Балалар, хыялны җитәкләп,
Мусалар юлыннан баралар...



...

Сине миннән юллар тартып алды,
Кызганмады инде еллары,
Җилләр: “Ул кайтмас...” – дигәч,
Бураннарга кушылып еладым...

Сине миннән читләр тартып алды,
Үзем дә сөйдем ятларны,
Безне уйлап саргайдылар
Каеннарның аклары...

Сине миннән давыл тартып алды,
Ярлар кушылмый – ерак аралар...
Таһир-Зөһрәләрне елатырлык
Безнең күңелдәге яралар.

Көнен-көнгә, аен-айга ялгап,
Дисбе тезәм ялгыз еллардан
Мин булып, бураннар гына
Чыгып елый хәзер юлларга...





**КЕРПЕ**

Борын-борын заманда керпеләрнең энәләре булмаган. Алар шуның өчен төлкеләрдән, бүреләрдән качып кына йөргәннәр. Үзләренә азык табар өчен, керпеләр төнлә генә чыга торган булганнар. Ләкин аларның көндез, кояш яктысында да йөриселәре килгән. Керпеләр уйлаганнар-уйлаганнар да агачлардан ярдәм сорамакчы булганнар. Беренче булып, алар каен янына барганнар да усал җәнлекләрдән сакланыр өчен ярдәм итүен сораганнар. Каен аларга болай дигән:

- Мин сезне кызганам, ләкин берничек тә ярдәм итә алмыйм шул.

Юкәдән дә шундый җавап ишеткәннәр керпеләр. Менә алар чыршы янына килгәннәр. Чыршы аларга:

- Курыкмагыз, мин сезгә ярдәм итәрмен, - дигән дә керпеләр өстенә үзенең сагызын тамызган. Шул сагыз өстенә ул күп итеп энәләрен тезгән һәм көрән төскә буяган.

Шуннан бирле керпеләр бер җанвардан да курыкмыйча, иркенләп яши башлаганнар.

***Ибраһимова Динара, 3 сыйныф укучысы***



## ӘНИЕМӘ ТЕЛӘКЛӘР

Иң кадерле әниемә
Теләк телисем килә,
Минем назлы сүзләрдән
Аның йөзләре көлә.

Озак яшә, әнием,
Син безгә әле терәк,
Җылы сүзең, киңәшләрең
Барыбызга бик кирәк!

Сәламәтлек белән яшә,
Шатлык булсын юлдашың,
“Мин бәхетле!” – диеп яшә,
Кайгыларың булмасын!

## САФЛЫК ТӨСЕ
***(уйлану)***

Җир йөзендә нинди генә төсләр юк! Ләкин миңа алар арасыннан яшел төс аеруча ошый. Чөнки яшел төс ул – мөселман төсе. Мин үзем Кырынды мәчетенә дин сабагы алырга йөрим. Шунда Коръән китапларының тышлары яшел төстә булуына игътибар иттем. Республикабыз Татарстан гербына һәм флагында да яшел



## ҮКЕНЕЧ

Безнең юллар дөрес түгел дип
Яшьлекне язып булмый яңадан.
Ялгызлыкта яшәр күңел дип
Кәккүк безгә еллар санаган.

Ялгыштым дип, кире кайту юк,
Адашсаң, юк чыгар сукмагы.
Аҗаган булып уйный баш очында
Язмышларның авыр тукмагы.

Язгы тәкыялар төсле җибәрәбез –
Агып китә бәхет суларда...
Сөйгән ярлар саубуллаша бара
Зәңгәр томан төсле юллардан

## ТАҢДА...

Яшел яфракта – ялгыз тамчы...
Әллә таллар елаган,
Яшьләрен коеп җиргә
Яңгырлармы моңланган

Әллә сөюдә алданганның
Күз яше тамган гөлгә...
Саксыз кагылдым, ахры –
Тәгәрәде тамчы җиргә...



*Люция Саматова, татар теле укытучысы*

**ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН…**

Читлекләрнең ишекләрен
Белмим, кемнәр бикләгән,
Алтын челтәр эчләреннән
Шагыйрь моңнар көйләгән.

Дөнья – читлек, диеп сызган,
Күңел яшьсез елаган.
Күкләргә очар канат
Очкайлары канаган.

Җырлый-җырлый дәшкән безгә,
Әллә елый-елыймы?
Гасырларны кичкән күңел
Бездән ирек сорыймы?

Кичер, шагыйрь, бәндәләрне –
Белмәгәннр бәһаңне.
...Зәңгәр күктән моң агыла,
Чү, таныш бит аһәңе!



төс төп урыннарның берсен алып тора. Димәк, дәүләтебез дә яшел төсне ярата.

Яшел төс ул – сафлык, җирдә андый төс булмаса, яшәргә дә күңелсез булыр иде. Иртә яздан бөтен тирә-як яшеллеккә күмелә, агачларда яшел бөреләр борын төртеп чыга, аннан соң яшел яфраклы бөдрә таллар, ак каеннар һәм башка агач-куаклар безнең тирәлекне ямьгә күмәләр. Безнең өй каршында биек булмаган тау битләре җәй көне ямь-яшел үләннәргә, аллы-гөлле чәчәкләргә күмеләләр. Җиләк вакыты җиткәч, без әнием белән шул тауга менеп, җир җиләге җыябыз. Аларны җыйганда мин яшел үләнгә чалкан ятып ял итәм. Шул чагында мине яшел үләннәр сыйпап сөяләр кебек тоела. Алай гына да түгел, яшел чикерткәләр, җырлашып, матур көйләр сузалар, табигатькә дан җырлыйлар. Менә шуңа күрә мин яшел төсне сафлык төсе, дип атыйм.

*Ахунова Динара, 6 сыйныф укучыс.*



**АК МОҢ ЯВА...**

Тәрәзәмнән күзем алмыйм:
Ап-ак кар ява.
Бу матурлыкка уралып,
Күңел моңлана.

Бар дөньямның хыялларда
Тулышкан чагы.
Ничек кенә җиткерим соң
Күтелгән таңны.

*Тимергазина Илүзә, 7 сыйныф укучысы*



## КӨЗ ҺӘМ КҮҢЕЛ

Җил очыра, өзеп агачлардан
Җәй хатирәсе – сары яфракны.
Яңгыр шакый күңел тәрәзәсен,
Никтер һаман көтеп ачканны.

Кыр казлары очып үткән якка
Мин бик карап калам, тик елмаеп,
Алар кабат кайтыр, язлар җиткәч,
Тагын китсәләр дә инде моңаеп.

Балан тәлгәше кызарып пешкән,
Миләшләр дә уттай яналар,
Көзнең шушы сихри мизгелләре
Күңелләрдә генә калалар...

***Вахитова Гөлназ, 7 сыйныф укучысы.***



Хәерле белән килсен яңа язлар,
Матурлансын газиз җиребез.
Игелектә, изгелектә үтсен
Көтеп алган һәрбер көнебез!

## ХӘТЕР КИТАБЫ

Күрмәдем мин сугыш ачыларын,
Күрдем әниемнең күз яшен.
Язлар җиткәч, Җиңү көннәрендә
“Хәтер китабы”ның юешен.

Елый иде әни сүзсез генә
Ачып сиксән икенче битен китапның –
Абыйсының исеме язылганын,
Бигрәк сагынды шул ул аны.

“Хәтер китабы”ның изгелеген
Кулга алу белән аңлыйсың.
Сугыш кырларында ятып калган
Солдатларның исемен барлыйсың.

Еллар үткән саен артсын иде
Батырлыкка булган ихтирам.
...Әниемнең күз яшьләре тамган
“Хәтер китабы”н кулыма алам...

Килеп җитә кеше тормышында
Соңгы сулыш алыр мизгеле
Ачкычыларның кайсы ярдәм итәр,
Ачар өчен оҗмах ишеген?

## ӨМЕТ ЧАТКЫСЫ


Калган гомерләрен белү өчен,
Тыңлый кеше кәккүк тавышын...
Кәккүк санаган еллар күп булса да,
Күп бирмәсен кәккүк сагышын.

Яз сулары алып китсен иде
Кешеләрнең барлык кайгысын.
Табигатьненең язгы ташуларын
Яратмаган кеше бармы соң?!

Шифа булсын иде һәркемгә дә
Кояш нурларының җылысы.
Чәчәк атсын иде күңелләрдә
Бөреләнгән өмет чаткысы.

Җылы яктан кошлар белән
Кайтсын иде тәннәр саулыгы.
Бәрәкәтле тормыш насыйп булсын,
Кимемәсен күңел байлыгы.





## ӘНИЕМ, КАДЕРЛЕМ

Минем әни бигрәк матур,
Ул мине назлап сөя.
Һәр көн иртән торганда:
"Үсеп җиттең бит!" – дия.

Без әнине яратабыз,
Һәрчак хөрмәт итәбез,
Бәйрәмнәрдә бүләк алып,
Аны тәбрик итәбез.

Яшәсен җирдә әниләр,
Якты булсын йөзләре.
Һәрчак шулай көлеп торсын
Аның матур күзләре.

***Әхмәтов Рифат, 8 сыйныф укучысы.***



## КЫШ БАБАЙ

Борын-борын заманда
Яшәгән, ди, Кыш бабай,
Барча халыкның теленнән
Төшмәгән, ди, Кыш бабай.

Килеп җитте ул безгә,
Күтәреп зур капчыгын,
Бүләкләр өләшкәч, бер читкә
Утырды ул, талчыгып.

Ул ял иткәндә, без аңа
Матур җырлар җырладык,
Биедек, уйнадык, көлдек,
Кемнәр генә булмадык!

...Тик шунысы кызганыч:
Булып чыкты ул кеше.
 - Каян белдең? – дисезме,
 Кыш бабай бит чишенде!

**УКЫТУЧЫМА!**

Бөтен гомерен балаларга биреп,
Таңнан төнгә янып көюче,
Күктә янган якты кояш сыман,
Тирә-юньне нурга күмүче – укытучым!

Һәрбер сүзе, җылы күз карашы,
Сабый күңеленең түренә үтүче,
Авырлыклар килсә, уртаклашып,
Сиздермичә ярдәм итүче – укытучым!

Кирәк чакта бераз кырыс булып,
Тыныч кына җавап бирүче,
Белем дөньясының баскычларын
Синең белән бергә үтүче – укытучым!

Рәхмәтемнең иң олысы сиңа булсын, укытучым!

***Бәшәрова Инзилә, 6 сыйныф укучысы***



**БӘХЕТ АЧКЫЧЫ**

Ачкычлары туры килмәгәндә,
Ачылмый бикләнгән йозаклар.
“Бәхет” дигән серле халәтнең
Ачкычларын кемнәр табалган?!

Ачкыч коя оста бер сәгатьтә,
Каршысына куеп өлгесен.
Бәхет ачкычын гына ясап булмый,
Үрнәкләре аның билгесез.

Кемдекр өчен бәхет – җирдә яшәү,
Гомерне бит булмый кайтарып.
Кемдер кеше гомерләрен өзә,
Кансызлыкны булмый аңлатып.

Берәү, эзләп бәхет ачкычларын,
Бала йортларына юнәлә.
Икенчесе, киресенчә эшләп,
Бала юклыгына сөенә.

Бәхет мизгелләрен арттырыр өчен,
Бертөрлеләр игелек өләшә.
Икенчеләр, комсызлыкка батып,
Туганыннан хәтта көнләшә.

Мәктәп өчен биреп бар көчеңне
Еллар арты еллар кичкәнсең.
Балаларның кереп күңеленә
Алар белән дөнья гизгәнсең.

Өлге булып яшь мөгаллимнәргә
Дөрес киңәшләреӊ биргәнсең.
Син лаеклы зур хөрмәткә бүген,
Ихтирам тоеп озак яшә син!

**ГОМЕРЛЕК ЯТИМНӘР**

Сугыш елларында ятимлекне
Татыганнар күпме балалар.
Безнең төбәктә дә яши алар –
Әтиләрен күрми калганнар.

Мылтык тавышлары булмаса да,
Сугыш кергән барлык өйләргә.
“Әттә” сүзен кат-кат пышылдаган
Тәпи киткән сабый төннәрдә.

Шул сабыйның саклап йокыларын
Утка кергән күпме әтиләр.
Яшәү көчен биреп баласына
Күкрәгенә кыскан әниләр...

Сугыш тәмам, әмма дәвам итә
Шул елларның ачы сагышы.
Ятимлекне һаман кичерә алмый
Күпне күргән сугыш баласы.





**ШАЯРТМА СИН, ӘТИЕМ!**

Менә көткән кар да яуды,
Мамыкка күмелде җир.
Әти әйтә: “Кар китерде
Ак сакаллы “господин”.

Сакаллы “господин” инде
Суык Кыш бабай була.
Матур йөзле “госпожа”
Кар кызы булып туа.

Алар килә бергәләп
Безнең белән уйнарга.
Күчтәнәчләр өләшеп,
Бәйрәм киче куярга.

Юк “господин” түгел ул
Кыш бабай уйный-көлә.
Безне сөендерер өчен
Бик тырыша, мин беләм.

*Сафиуллина Айсылу, 8нче сыйныф укучысы*



## СИҢА

Үтте инде бала чаклар,
Әллә кайда калды мәхәббәт,
Шул вакытта сине күрдем –
Күрүемә зур рәхмәт.

Күрү белән гашыйк булдым
Синең барлык җиреңә:
Йөзеңә, күзләреңә,
Хәтта назлы исемеңә.
Кайда барсам, нишләсәм дә
Күз алдымда бары тик син.
Синсез тормыш - тормыш түгел,
Син булмасаң, нишлим мин?

Чын-чынлап мин сине сөям
Ышан миңа, матурым.
Барлык булган хисләремне
Сиңа бирәм, алтыным.

Юк дөньяда андый мәхәббәт,
Булган кебек безнең арада.
Беркемгә дә сине бирмәм,
Булсаң минем янымда.



Үзебез дә мәктәп бусагасын
Тәүге тапкыр атлап кердек бит.
Укытучы апа күзлпеннән
Дөнья матурлыгын күрдек бит.

Озын-озын кебек тоелса да,
Бик тиз үтә мәктәп еллары
Тик кайтарып булмый балачакны
Сагындыра яшьлек юллары...

Кешелекле булсын килер буын
Компьютерлар чорнап алса да.
Оныкларга карап сөенергә язсын
Мәктәп белән саубуллашканда.

## ВЕТЕРАН УКЫТУЧЫГА

Укытучы! Синең язмышыңны
Аерып булмый мәктәп тормышыннан.
Шатлыкларың , барлык борчуларың
Башланган бит мәктәп сукмагыннан.

Күпме бала өчен көенгәнсең,
Күпмесенә белем биргәнсең.
Язлар саен күпме укучылар
Ерак юлга чыгып киткән соң?

Ханымнар һәм әфәнделәр килгән,
Танышлар да кебек үзләре.
Ә карасаң, күзләр шул ук икән
Шаян очкын чәчә күзләре.

Саулармысыз, газиз классташлар,
Хуш кайттыгыз, рәхим итегез.
Очрашулар матур гына үтсен.
Рәхәтләнеп яллар итегез,
Яхшы кәеф белән китегез!



***Рима Зарипова, башлангыч сыйныф укытучысы***

**ТӘҮГЕ ТАПКЫР**

Тәүге тапкыр быел мәктәпкә
Оныгым дәртләнеп җыена
Китап, костюм, сумкасы –
Әкрен-әкрен бар да җыела.

Оныгыма карап искә төшерәм
Өч баламның мәктәп елларын.
Бәхет бит ул – күтәп алу
Сабыеңның укып кайтканын.



**ХӘТЕРЕМДӘ...**

Әле һаман минем хәтеремдә
Сине күргән беренче көнем.
Мизгел...Һәм мин гашыйк булдым
Аңламадым – әллә төшем бу, әллә өнем?

...Исеңдәме бергә йөргәнебез,
Йолдызларга карап хыяллану...
Чиксез бәхет була иде безгә
Яңа туган таңны каршы алу.

Тик нигәдер, җаным, без югалттык
Мәхәббәтнең генә кадерен.
Син бит хәзер башка белән,
Күңелемдә яра, бәгырем.

Вакыт үтте. Мин аңладым хәзер
Тик бер дәва – ул син җаныма.
Хыянәтне мин кичерә алам
Тик син генә кайтчы яныма.

## ДӨНЬЯ МӘГЪНӘСЕ

Шушы моңсу салкын төндә
Уйланасым килә дөнья турында.
Без, кешеләр, бу тормышта
Яшибез соң нинди урында?

Уңга баксаң,сулга баксаң,
Ни күрерсең, адәм баласы?
Берсе талый, берсе урлый-
Һәрберсенең килә байыйсы!

Бу дөньяның якты мизгелләрен
Алар күрә бары тик байлыкта.
Кирәкми бит алар өчен
Яшәүләре таза-саулыкта.

Байлык өчен алар риза
Әйләнергә ерткыч хайванга,
Намусларын җиргә салып
Аяк белән басып таптарга.

Уян,дустым! Булма андый!
Булма шайтан иясе.
Башкада бит бу дөньяның,
Бу дөньяның мәгънәсе!

***Ситдыйков Марсель, 11 сыйныф укучысы***



Бу илаһи гүзәллекне
Аңлаучылар бик сирәк.
Табигатьнең матурлыгын
Тоя белергә кирәк.

## КЛАССТАШЛАРГА

Классташны күрдем әле беркөн,
Туктап хәл-әхвәлләр сорады.
Бу күрешү мине ак алъяпкыч кигән,
Сабый чакка гүя кайтарды.

Балачакны эзләп, мәктәбемә керәм,
Таныш миңа аның һәр җире.
Шул малайлар, наян кызлар гына
Таныш түгел инде, икенче.

Бүген очрашуга килдек менә
Таралыштык кебек кичә кич.
Ә санасаң, инде ул көннән соң,
Чирек гасыр үтеп киткән бит

.

Сихри төнге урман учагының
Тоя белдек без генә ямен.
Көлгә күмеп пешкән бәрәңгенең,
Әле дә сизәм авызда тәмен.

Балачакка кайтып киләм кайчак,
Күңел һаман сабый чорында
Сөенәм: туган йортым, әнкәм исән,
Өзелеп сагынып кайткан чагында.

## ЮКСЫНУ

Сагындым ла авылымның
Җиләкле болыннарын,
Шул болында чабып йөргән
Уенчак колыннарын.

Хәтфә келәмдәй аланда
Чикерткәләр сайраша.
Авылымның уңган халкы
Печәнлектә кайнаша.

Шунда үскән шомырты дә,
Сәламли күк елмаеп.
Каен җиләге күз кыса:
“Өзегез, без калмаек!”






## ХӘТЕРЛИМ МИН ӘЛЕ БҮГЕНГЕДӘЙ...

Беренче сыйныф... Беренче укытучы... Ул мәңгегә безнең күңел түрендә калачак. Белем иленең тәүге баскычыннан атлатучы бу зат һәрвакыт сагындыра, берничә генә мизгелгә булса да, ул чакларны кире кайтарасы килгән минутлар күп була.

Иң беренче тапкыр безне , өч кечкенә генә сабый баланы каршы алган укытучым Эльмира Зиннәтуллина бүгенгедәй күз алдымда тора: матур киемле, биек үкчәле туфли кигән, шат йөзле иде ул. Ә күзләре... Шундый ягымлы, шундый үз итеп карый иде безгә укытучы апа. Без хәтта аның чит кеше икәнен бөтенләй онытып, шунда ук аны үз иттек.

Эльмира апа безнең өчен ярдәмче, озатучы, киңәшче була белде. Ул безне үзебезгә ышанырга, кыенлыклар алдында каушап калмаска өйрәтте. Укытучы апабызның мавыктыргыч дәресләрен, бергәләп йомшак уенчыклар теккән, төрле конкурсларда катнашкан, гөлләр үстергән мизгелләрне ничек инде онытып булсын!

Эльмира Хәйдәр кызы безнең һәркайсыбызга игътибарлы булды. Күзебезгә карап, күңелебезне аңлады. Укытучы апабызның сабыр йөзен, бераз гына арыган, ләкин ягымлы караган күзләрен көн саен күрү минем сабый

йөрәгемне иксез-чиксез шатлык белән тутыра иде. Әйе, безнең апабызга карата игътибарсыз булганыбызны мин бүген генә аңлыйм. Без берни күрмичә, сизмичә яшәгәнбез икән бит! Апабызың күз төпләренә яшеренегән, арыган йөзендәге сизелер-сизелмәс җыерчыкларын без күрмәгәнбез, әллә ул күрсәтмәгән... Ул бит укытучы гына түгел, тормыш иптәше дә, әни дә, килен дә...

Беренче укытучым бүгенге көндә дә безнең укуыбыз, уңышларыбыз белән кызыксынып тора. Һәрчак үзенең төпле, акыллы киңәшләре белән ярдәм итә.

Мин көн дә Эльмира апаның сыйныфы яныннан узып китәм.Аннан бүген дә беренчеләрнең тырышып-тырышып укырга өйрәнгәннәре ишетелеп тора. Күңелемдә беренчеләргә карата көнләшү хисе кузгалып куя. Алар алдында әле ачылмаган зур дөнья җәйрәп ята. Яннарында Эльмира апа кебек остазлары булганда, алар югалмаслар. Ә безгә инде тиздән туган мәктәбебез белән саубуллашыр чак җитә.Бу көн бит бик тиздән килеп җитәчәк. Укытучыларым, туган мәктәбем белән ничек итеп саубуллашырмын икән мин?! Аерылу мизгелләре бик тә, бик тә авыр булачак, ләкин сүз бирәм: мин СЕЗНЕ беркайчан да онытмам! Сез биргән белемнәр, тәрбиягез мине гомерем буе озатып барачак. Беренче укытучым, 11 ел буе бер гаилә булып яшәгән укытучы абый-апаларым минем өчен һәрвакыт иң күркәм, иң галим, иң гадел, иң гүзәл зат булып калачак.

***Җаббарова Гөлинә, 11 сыйныф укучысы***



# УКЫТУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ



***Нәсимә Гарифуллина, тарих укытучысы***

**БАЛАЧАККА КАЙТАМ**

Балачакка кайтып киләм кайчак,
Йөрәк һаман сабый чорында.
Күңелем белән урамнарны иңлим,
Өзелеп искә төшкән чагында.

Бер дә истән чыкмый авылымның,
Бәпкә үләнле борма сукмагы,
Ак яулыклы күркәм әбиләре,
Эшләпәле зирәк картлары.

Кечкенәдән уйнап үскән дуслар
Сагындырып искә төшәләр.
Инде ничә еллар үтсәләр дә,
Гүя алар шунда көтәләр.